# Нәсыйхәт

җомга
26
август 2011
№ 7

**Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән**
**Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы**




## Мөхәррир сүзе

**Безне һидәяткә күндергән, күңелләребезгә иман нурын иң зиннәтле нәрсә итеп урнаштырган Аллаһы Тәгаләгә барча мактауларыбыз булсын. Пәйгамбәребезгә рәхмәт-салаватларыбыз, сәхәбәләренә, аңа изгелектә иярүчеләргә догаларыбыз барып ирешсен.**
**Хөрмәтле мөселманнар! Түземсезлек белән көтеп алынган Рамазан ае да ахырына якынлаша. Бу вакыйга бер яктан күңелгә шатлык, икенче яктан ямансулык өсти. Шатлык- чөнки гает бәйрәме якынлаша, ямансулык-чөнки безгә күп кенә бүләкләр белән килгән кадерле кунагыбызны озатабыз. Рамазан ае безгә бик күп кыйммәтле дәресләр бирде. Ул безгә нәфесне җиңәргә, күңелне пакъләргә, хайван сыйфатларын җиңәргә, Аллаһ белән якынаерга ярдәм итте. Әмма Рамазан ае китә дип без изгелекләр кылудан туктамаска тиешбез. Бәлки киресенчә, аларны тагын да күбрәк итеп эшләп, Аллаһның ризалыгын алырга тырышу зарур. Чөнки калган айлар да Аллаһының айлары, калган көннәрдә дә Раббыбыз безгә үзенең нигъмәтләрен бирүен дәвам итә. Һәм ул нигъмәтләр чиксез. Шуңа күрә дә без бүтән айларда да Бөек Хуҗабызны данларга һәм аңа шөкер итәргә тиешбез.**
**Хөрмәтле районндашлар! Рамазан ае безгә юмартлык дәресләрен дә бирде. Шунлыктан Раббыбызның ачуын китерә торган саранлыгыбыздан арынсак иде. Бүгенге көндә мәдрәсә яңа уку елына әзерләнә. Ел дәверенә шәкертләрне ризык белән тәэмин итү, укытучыларга хезмәт хаклары түләү өчен финанс булдыру җиңел хәл ителми. Бу эштә бергә һәм бердәм булсак кына гамәлләребез нәтиҗәле булыр. Мәдрәсәбезне ятим итмик, малларыбызны кызганмыйк, көчебездән килгәнчә гыйлем йортына ярдәм итик.**
**Хөрмәтле кардәшләр! Раббыбыз тоткан уразаларыбызны, кылган изгелекләребезне кабул итсә иде! Киләчәк Рамазан аен да исәнлектә каршы алып, уразаларны тотарга насыйп итсә иде!**

## Яңалыклар

### МӨСЕЛМАН ЯШЬЛӘРЕ ӨЧЕН ИФТАР

22 августта Мамадыш мәдрәсәсендә мөхтәсибәт белән берлектә район мөселман яшьләре җыены уткәрелде. Мәҗлестә 70ләп кеше катнашты. Сөйләшүне район мөхтәсибе Илһам хәзрәт ачып җибәрде, вәгазь сөйләде. Кунаклар бүгенге исламга бәйләнешле күп кенә проблемаларны уртага салып сөйләштеләр, шулай ук үзләрен борчыган сорауларына җавап алдылар. Дини темага викторина үткәрелде. Мәҗлестә муниципаль район башкарма комитеты рәисе вазыйфаларын башкаручы Илнар Фәнил улы да бар иде. Ул мондый җыеннарны ешрак үткәрергә кирәк булуын ассызыклады.

### ИНВАЛИДЛАРГА ИГЪТИБАР

23 августта Мамадыш мәдрәсәсе иганәчеләр ярдәме белән оештырылган ифтарга 40лап инвалидны җыйды. Мәҗлесне мәдрәсә җитәкчесе Габдрахман хәзрәт ачып җибәрде, килгәннәргә җыелулары өчен рәхмәтен җиткерде. Ураза тотуның әһәмияте, Рамазан шәриф аеның фазыйләтләре турында сөйләп үтте һәм ураза тотучыларга сабырлык теләде, әлеге изге айда күбрәк изге гамәлләр кылырга чакырды.

### СУГЫШ ВЕТЕРАННАРЫНА УРЫН ТҮРДӘН

Сугыш ветераннары мәдрәсәгә зыяратка бик шат булдылар. Алар ислам диненең үсүенә һәм мөселман яшьләренең сафлары артуга карата шатлануларын белдерделәр. Тыныч тормышта яшәүнең кадерен белергә чакырдылар. “Җәмгыятебездә соңгы елларда күренгән тискәре күренешләргә – эчкечелек, наркомания, тәмәке тарту һ.б. начар гадәтләрнең тамыр җәймәвенә уртак көч белән генә юл куелмавы мөмкин!”- диде алар. Очрашу барышында ветераннар вәгазь тыңладылар, соңыннан аларга чәй эчертү оештырылды.

### ЯҢА УКУ ЕЛЫНА ӘЗЕРЛЕК

Мәдрәсә бинасында яңа уку елына әзерлек бара. Уку җиһазлары ремонтлана, буяу һәм чистарту, уку бүлмәләрен тәзекләндерү эшләре башкарыла. Авырлыкларга карамыйча, бу эшләрне мәдрәсә үз көче белән алып бара.

### КАБУЛ ИТҮ КОМИССИЯСЕ ЭШЛИ

Мәдрәсәгә укырга керергә теләүчеләр өчен кабул итү комиссиясе эшли. Биредә уку-укытуга кагылган сорауларга җавап бирәләр, документларны, белешмәләрне кабул итәләр. Белешмәләр өчен телефон: 89172802391, 89093148644.

### МӨГАЛЛИМНӘР ИФТАРЛАРДА

Мәдрәсә мөгаллимнәре районның төрле авылларында уза торган ифтар мәҗлесләрендә актив катнаша. Мәҗлесләр барышында алар килгән халыкның сорауларына җавап бирәләр һәм аларга файдалы вәгазь-нәсыйхәтләрен җиткерәләр, мәдрәсәгә укырга чакыралар.

### ИҢ КУЛАЙ УРЫН – МӘДРӘСӘ

Мәдрәсәдә ел дәверенә шәкертләргә җитәрлек ризык туплау, укытучыларга хезмәт хакы түләү өчен финанс булдыру – гаять авыр хезмәт. Мәдрәсә халыкның ярдәменә мохтаҗ. Хөрмәтле районндашлар, гошер һәм фитра сәдакаларын бирү өчен мәдрәсә – иң кулай урын.

# РАМАЗАННЫҢ СОҢГЫ УН КӨНЕ




**Рамазан аен ел буе сагынып көтсәк тә, газиз кардәшләрем, изге көннәр сизелми дә үтте. Көн арты көн килеп Раббысына тугры бәндә кадерле вакытларны изге гамәл, Коръән укуга сарыф итә. Тоткан ураза калебне йомшарта, торган кыямнар сабыр, әхлаклы итә, укыган аятьләр гафиллектән уята. Тән итагать кыла, тел зикер итә, җан уйлана, гыйбрәт ала. Олуг кунакның китәр вакытлары җиткәч, кадере арта.**

Ул көннәрдә иман әһеленең изгелекләре өстәлә, “Рәхмәтенә ирешермен, гөнаһымнан пакъләнермен, уттан котылырмын”–дигән өметләр арта. Гайшә р.г. әйтә: “Аллаһының илчесе Рамазанның ахыргы ун көнендә, башка көннәренә караганда ныграк иҗтиһад күрсәтте.” (Мөслим). Мәшһүр галим Хәсән Әл-Бари әйтә: “Рамазанның ахыргы ун төне җитсә, Аллаһының илчесе с.г.в. төннәрен намазда үткәрде, гаиләсен уятты. Гыйбәдәттә аеруча зур тырышлык күрсәтте һәм изәрен (чалбарын) катырак бәйләде”. Аллаһының илчесе Рамазан аеның ахыргы ун төнен мәчеттә үткәрде һәм : “...Кадер төнен, Рамазан аеның ахыргы ун төнендә эзләгез”,-диде. (Бохари һәм Мөслим) Әйе, Рамазанның ахыргы ун төне, безгә башына таҗ кигән Кадер төнен алып килә. Ул төн чын мәгънәсендә күп кенә бөек вакыйгаларны үз эченә алган. “Дөреслектә Без аны (Коръәнне) Кадер төнендә индердек. Кадер төне мең айдан да хәерлерәктер. Ул төнне Аллаһының теләге илә барча әмерләр белән фәрештәләр һәм Рух (Җәбраил) иңә. Ул таң беленгәнче иминлектер”. (Кадер сүрәсе). Бу төн Аллаһ каршында иң кодрәтле һәм иң хөрмәтле төндер. Кадер төнендә, ел әйләнәсенең язмышы тәкъдир кылына. Аллаһ Тәгалә әйтте: “ Ул төндә һәрбер хикмәтле эш бүленә”. (Духан 4). Бу төндә Аллаһ үз колларына тагын да мәрхәмәтлерәк, тагын да рәхимлерәк, тагын да юмартрак була. Бу төндә кешеләрнең яшәү энергиясе күпкә арта торган була.

**КАДЕР ТӨНЕ КАЙЧАН БУЛА?**

Шиксез, кадер киче һәр елның Рамазан аенда була. Әмма бу айның кайсы вакытында булуы сер булып кала. Бу мәсьәләдә галимнәр төрле фикердә. Берәүләре Кадер төнен 21 көнендә, икенчеләре 23, 25, 29 диләр. Күбесе 27 дигән фикердә. Пәйгамбәребез с.г.в. мөбарәк, мөкатдәс төнне соңгы ун төннән эзләде. “Кадер төне–Рамазанның ахыргы ун төнендә. Кем Аларны уяу үткәрә, Аллаһ аның кылган һәм кылачак гөнаһларын кичерә. Бу да так санлы төндә. Тугызынчы, җиденче, бишенче яки өченчесендә”. Әмма кайбер галимнәрнең фикеренчә, кадер кичен Рамазан аеның һәр төнендә уяу булып, гыйбәдәтләр кылып, догада булып эзләү хәерлерәк.

**КАДЕР ТӨНЕНЕҢ ГАЛӘМӘТЛӘРЕ**

Пәйгамбәребез с.г.в. әйтте: “Кадер төненең галәмәтләреннән, ул якты ай кебек, саф, нурлы тыныч, имин, салкын да, эссе дә түгел, бу кичтә явым-төшем булмас. Һәм ул төнне бер йолдызга да атарга хәләл түгел”. “Ул көннең кояшы нурсыз, тулы ай кебек. Шайтанга ул көнне кояш белән чыгарга хәләл булмый”.

Бу кичнең, башка кичәләрдән аермалы буларак, үзенең махсус нуры бар.

**КАДЕР КИЧЕН НИЧЕК КАРШЫЛАРГА?**

Кызганыч, бүген без яңа елны ничек каршы алырга икәнен беләбез, ә мең айдан да хәерлерәк булган кадер кичен ничек үткәрергә белмибез. Әлбәттә, бу төнне позитив фикер белән каршы алырга кирәк. Аллаһ без сораган һәр әйберне бирергә кодрәтле, шуны онытмыйк. Үзебезнең догаларыбызда, эшләребездә Аллаһның рәхмәтенә өметле булу ләзем. Гайшә р.г Пәйгамбәребездән с.г.в.: “ Кадер төненә ирешсәм, нәрсә дип әйтим?” – дип сорагач, Ул с.г.в. : “Аллаһүммә иннәкә Гафүввун түхиббуль гафвә фәгфу гаҗим – дип әйт” – диде. (Тирмизи)

**ГАЕТ НАМАЗЫ**

Шәүвәлнең беренче көне гаед-фитр көне – ураза гаете. Рамазан рузасы тәмам булганнан соң бәйрәм ителә торган көндер. Бу көндә имамга кушылып, гает намазын уку һәр мөселманга тиештер. Рамазан гаете намазына барганда, юлда тыныч тавыш белән тәкъбир әйтеп бару күркәм гамәлдер. Бәйрәм намазы үзе ике рәкагатьтән тора һәм аерым-аерым түгел, ә бергәләп–җәмәгать белән укылыр. Беренче рәкәгатьтә, «Сөбхәнәкә» укылганнан соң, куллар өч тапкыр колакларга күтәрелә. Беренче һәм икенче мәртәбә куллар ике якка төшерелә, ө өченчесендә кендек астында тоташалар. Шуннан сон, «Фатиха» һәм өстәмә бер сүрә укыла. Соңыннан рөкүгъка һәм сәҗдәгә кителә. Икенче рәкагатькә торып баскач, «Фатиха» һәм өстәмә тагын бер сүрә укыла. Алга таба куллар өч мәртәбә колакларга күтәрелеп, ике якка төшерелә. Дүртенче тәкъбирдә куллар күтәрелми, ә рөкүгъка кителә, алга таба сәҗдә кылына. Димәк, кагыйдә шундый: ике мәртәбә төшер, бер мәртәбә тоташтыр; өч мәртәбә төшер, бер мәртәбә иел.

**ГАЕТНЕҢ ФАЗЫЙЛӘТЛӘРЕ**

Гает – бәйрәм, иман ияләренең дөньядагы шатлык вә сөенеч көннәре. Аллаһка камил итагатькә, Аллаһ вәгъдә кылган изге гамәлләрнең савабына сөенеч. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әйт: Бу Аллаһның юмартлыгы вә рәхмәте. Моның өчен шатлансыннар. Дөреслектә, бу аларның җыйган нәрсәләреннән хәерлерәктер». («Юныс», 58). Гает – шөкер вә зикер көне. Гает – күпләр уйлаганча, уенкөлке, кәеф-сафа корып утыра торган көн түгел, бәлки Аллаһны искә төшерү, Аның бәндәләренә булган нигъмәтләрен күрсәтү, Аңа хәмде-сәнә әйтү, бар нигъмәтләр өчен шөкер итү көне. Аллаһ үзенең бәндәләренә ураза көннәре үткәч, тәкъбир әйтеп, шөкер итәргә боерды: «Ул билгеле көннәрне ахырга җиткерүегезне һәм Аллаһ сезне туры юлга күндергәне өчен Аны бөекләвегезне тели. Бәлки шул ук вакытта сез Аллаһка шөкер итәрсез».

**ГАЕТ КӨНЕНЕҢ ӘДӘПЛӘРЕ**

Гает көннәрендә руза тоту рөхсәт ителми. Әбү Сәгыйть (р.г.) тапшыра: «Аллаһының илчесе ике көннең уразасыннан тыйды: ифтар һәм корбан көннәре». (Бохари, Мөслим). Кояш баеп, гает төне кергәннән алып, гает намазына кадәр тәкъбир әйтү сөннәт булып тора. Ир кешеләр мәчетләрдә, өйләрендә, базарларда, юлларда гыйбадәтләрен һәм шатлыкларын белдертеп тавыш белән тәкъбир әйтә алалар. Гает көнендә бер-береңне сөендерү, табыннар хәзерләп кунаклар чакыру, аларны сыйлау, үзеңә туган-кардәшләреңнең хәлләрен белеп кайту, «Аллаһ синнән дә миннән дә кабул итсен», дигән тәбрикләүләр киңәш ителә. Гает көнендә гает намазын калдырудан сакланырга кирәк. Аллаһының илчесе галәйһиссәләм безгә гает намазына госелләнеп, исле майлар сөртеп (ирләргә), иң матур киемнәрне киеп килергә киңәш итте. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм үзе гаеткә Йәмән җирлегеннән алып кайткан иң затлы киемнәрен кигән.

**ИЗГЕЛЕК ДӘВАМ ИТӘ**

Рамазан аеның күркәм сыйфатлары күп. Шуларның берсе – ураза тотучыларның ай буе кылган игелекле гамәлләренең Рамазаннан соң да дәвам итүе. Рамазан ае дәвамында күп кенә мөселманнар элек кылмаган бишвакыт намазын укый башладылар, иманын ныгыттылар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.) хәдис-шәрифендә болай әйтә: “Гамәлләрегезнең иң яхшысы дәвамлы булганыдыр”. Иң мөһиме–яхшы гамәл гомер буе эшләнергә тиеш. Рамазан аеннан соң шәүвәл аенда 6 көн ураза тоту шулай ук хәдискә таяныла. Анда болай диелә: “Кем ки Рамазан дәвамында ураза тотса, аннан соң шәүвәл аенда да аңа тагын 6 көн өстәсә, ел буе ураза тоткан кебек булыр”.

Мөхтәрәм газиз кардәшләрем, Рамазан шәрифне ганимәт белеп, изгелекләр, хәерле гамәлләр кылып калыйк. Аллаһ тәгалә дини вә дөньяви эшләребездә уңышлар, үсеш бирсен. Үзенең һидаять юлыннан адаштырмасын. Гаетләребез мөбарәк булсын, җөмләбезгә хәерле гомер, һәм балаларыбызга Раббуль Гыйззә тәүфыйкъ-истикамәтләр, шәкертләребезгә гыйлем-нәфыйк, дин һәм милләтебезгә хәерле хезмәтләр мияссәр кылып, җөмләбезнең күңелләрен пакъ, иманнарыбызны сәламәт кылсын. Гаид шәриф бәйрәмнәребез барчабызга мөбарәк булып, киң ризык, дин һәм дөньяларыбыз тереклегендә Җәнабе Аллаһ тәкрарларын күрергә насыйб әйләсен.

***ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН***

*әзерләде.*

# Юмартның малына бәрәкәт иңә

**“Коръәндә мәрхәмәт итү хуплана, мәсәлән: “Шатлыкта да, кайгыда да малларын сарыф итүчеләргә... Хакыйкатьтә, Аллаh яхшылык эшләүчеләрне сөядер!”**

Пәйгамбәр (с.) хәдисләрендә изгелек кылуга, динебез ныгуына һәм халык файдасына юнәлтелгән сәдакалар итүгә кызыктыручы вәгъдәләр бик күп. Мәсәлән, Мөслим Сахихында китерелүче хәдисне карап үтик: «Адәм баласы вафат булганнан соң бөтен гамәле киселә, мәгәр дә ошбу гамәлләр генә артыннан барып торыр: халык файда алырлык рәвештә нәшер кылып калдырган гыйлеме, изге баласы, мирас итеп калдырган Коръән Кәрим нөсхәсе, бина кылган мәчете, мосафирлар файдалансыннар өчен салдырган йорты, агызып калдырган елгасы, үзе сәламәт вакытында хәер өчен биргән сәдакасы. Шушы нәрсәләрнең саваплары үзе артыннан һәмишә барып торыр». Күренгәнчә бу хәдистә мөселманнар өчен изгелек кылу буенча тулаем бер программа күрсәтелгән.

Дин юлында ярдәм бирү әһәмиятен түбәндәге хәдис күрсәтә: «Ярты хөрмә сәдака кылып кына булса да, уттан сакланыгыз, моны тапмасагыз, сораучыга яхшы вә йомшак сүз белән, кайтарыгыз» (Бохари, Мөслим). Тирмизидә риваять ителгән хәдистә әйтелгәнчә, «кыямәт көнендә малын нинди җирләргә тотуы хакында сорау булмый торып, адәм баласының аяклары баскан мәхәббәтен аулыйсыбыз килә. Ә юмартлык нәп-нәкъ Аллаһының яратуына китерә. Тирмизидә китерелә: «Аллаһы Тәгалә юмарт һәм юмартларны сөя».

Сахих Мөслимдә риваять ителә: «Хак Тәгалә кыямәт көнендә адәм баласына: «И, адәм баласы! Мин хаста булдым, син минем хәлемне сорамадың»,- диде. Адәм баласы: «И, Раббым!

**«Бер адәм сәдака бирү ишеген ачты исә, Аллаһы Тәгалә аның малында бәрәкәтен арттырыр...» Хәдис.**

жиреннән аерылмаслар». Киләчәктә андый сорау булачагын белү безне, әлбәттә, динебез файдасына хеерләр бирүгә әтәрергә тиешле. Янә хәдис сүзе белән әйтсәк: «Бер адәм сәдака бирү ишеген ачты исә, Аллаһы Тәгалә аның малында бәрәкәтен арттырыр...» Шуңа күрә сәдака беркайчан да малларыбызны киметмәс, ә бәлки аны арттырыр, бәрәкәтле итәр. Мөслимдә китерелә: “Сәдака малны киметмәс», чөнки кал¬гган мал афәт вә казалардан имин булыр, бәрәкәт хасил итү сәбәпле сәдака бушка булмаячак”. Безнең һәрберебезнең Аллаh

Мин синең хәлеңне ничек сорый алам? Син бөтен галәмнәрне тәрбия итүчесең!» - дигәч, Аллаһы Тәгалә: «Белмәдеңме, минем фәлән бәндәм хасталанды, син шуның хәлен сорамадың, әгәр дә аның хәлен сорарга барган булсаң иде, минем рәхмәтемне шунда тапкан булыр идең!»- диер. Аллаһы Тәгалә: «И, адәм баласы! Мин синнән ашарга сорадым, син бирмәдең!» - диер. Адәм баласы: «И, Раббым, мин сиңа ничек ашарга бирә алыйм? Син бөтен галәмнәрне тәрбия итүчесең!» дигәч, Аллаһы Тәгалә: «Белмәдеңмени фәлән бәндәм синнән ашарга сорады, син шуны бирмәдең, аңа ашарга биргән булсаң иде, аның савабын минем хозурымда тапкан булыр идең!» - диер». Күрәбез ки, сәдака бирүне инкяр кылу үзе нинди шелтәгә илтә, ул Раббыбызны инкяр кылуга бәрабәр итәрәк сурәтләнә.

Сахих Мөслимдә китерелә: «Сәдаканың иң саваплысы үзең сәламәт һәм дә мал җыярга ярата, фәкыйрьлектән курка, байлыкны арзу кыла торган вакытта биргән сәдакадыр. Игътибарсызлык кылма, үлем хасталыгы килеп җиткәннән соң фәлән кешегә фәлән кадәр вә фәлән кешегә фәлән кадәр биреләсе иде дия башларсың, хәлбуки бу вакытта маллар варисларга калган вә синең ихтыярың беткән булыр». Күпләребезнең якын кешеләре инде бу якты дөньядан мәңгелеккә күчкәннәр. Мәрхүмнәрнең теге дөньядагы хәлләре турында без, әлбәттә, борчылабыз, аларга багышлап догалар да кылабыз. Әмма догадан тыш без әрвахларга багышлап төрле сәдакалар да бирә алабыз. Шуңа күрә, ахирәт сәфәренә күчкән якыннарыбызга игелек эшлик, мал-мөлкәтебезнең бәрәкәтен арттырып үзебезне бәла -казадан саклыйк дисәк, Аллаh ризалыгы өчен хәер-сәдакаларыбызны саранланмыйк.

**Мәгълүм булганча, җир йөзендәге барлык төр яшелчәләр, җиләк-җимешләр Аллаһының нигъмәте илә һәм ул ирештергән файдалы яңгырлар, тиешле булган һава торышлары сәбәпле нәтиҗәле уңыш бирә ала. Шуңа күрә һәр кеше шөкер итү йөзеннән һәм киләсе уңышның мул булуын кайгыртып гошер бирергә тиеш.**

## Гошер – Аллаh әмере

Яңгыр суы белән үскән уңышларның - уннан берен, сугару юлы белән үскән уңышның, егермедән берен гошер итеп бирү зарур. Бу төр зәкәт һәр кешегә мәҗбүри, тиешле зәкәт категориясенә керә. Мөмкинлеге була торып гошер чыгармаган кеше, үз өстенә бик зур гөнаh алган була. Бу катгыйлык зәкәт түләмәүченең Аллаһның әмеренә буйсынмау белән аңлатыла. Аллаһы Тәгалә әйтте: “Ий, мөэминнәр! Кәсеп итеп тапкан малларыгыздан һәм Без сезнең өчен җирдән чыгарган уңышлардан яхшысын Аллаh күрсәткән урыннарга бирегез! Әмма начар нәрсәләр аралаштырып бирмәгез. Шундый малны сезгә бирсәләр, әлбәттә, ул начар нәрсәне күзегезне йомып, чыраегызны сытып кына алыр идегез. Белегез, Аллаh чиксез бай һәм мактаулы”. ( “Бәкарә” сүрәсе, 267 нче аять). Икенче аятьтә Аллаh болай дип әмер итә: “... өлгергәч һәрберсенең җимешләрен ашагыз һәм уңышларын алганда тиешле өлешен сәдака итеп бирегез!...” (“ал-Ангәм” сүрәсе, 141 аять) Шушы аяти – кәримәләргә бинаян җирдә үстергән һәр әйбернең уннан берен, су сибеп үстерелгән яшелчәләрнең, егермедән берен гошер итеп бирү тиеш була. Имам Әбү Хәнифәнең фикеренчә, гошер бирер өчен малның тиешле күләмгә җитүе зарур түгел. Шул исәптән гошернең нисабы булмыйча, җиләк-җимеш, яшелчә күпме бар шул күләмнән түләнергә тиешле була. Гошер уңышнын, яхшы өлешеннән генә бирелә, черек, вак, бозык өлешеннән гошер чыкмый. Бал 16 кг нан артса, уннан бере гошер булып бирелә, әйтик, 15 кг балдан гошер юк, 17 кг нан 1 кг 700 гр гошер чыга. Исламнын, өстенлеген аңлату өчен мөселман булмаган кешеләргә дә зәкәт һәм гошерне бирергә ярый. Гошер фәкыйрь, мескен, инвалид кешеләргә, толларга, ятимнәргә, шәкертләргә, бурычлы кешегә, ниндидер каза күргән кешегә, зәкәт җыючыга, дин хезмәтендә булган кешегә бирелергә тиешле. Биргәндә, зәкәттән булсын, дип, ниятләргә кирәк. Гошерне әтиәниеңә, әби-бабайларга, үз балаларыңа, ир-хатынына, хатын – иренә, байларга, оныкларга бирү ярамый.

Безнең төбәкләргә килгәндә элек гошер җыюлар гадәти тиешле бер йола рәвешендә үтәлә торган булган. Гошер ярдәмендә мәдрәсәләр һәм мәчетләр үз эшчәнлекләрен тулы канлы итеп алып бара алганнар. Бүген исә, мәчетләр, мәдрәсәләр үз көннәрен үзләре күргән мәлдә, финанс ягыннан тотрыксызлык чорын кичергәндә, гошер мәсьәләсе тагын да актуаль булып тора. Афәтләрдән, бәла-казадан, Аллаh ачуыннан ерак булыйк дисәк, Раббыбыз биргән ризыкларыбыздан һәм малларыбыздан өлеш чыгарыйк. Шундый булсак кына табынарыбыз мул, кукләребез аяз булыр.

Материалларны **ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН** әзерләде.

# “Авызымны ачтым иман белән...”

**Пәйгамбәребез сәхабәләренә Рамазан аенда ураза тотучы кешеләрне мәҗлескә җыеп, авыз ачтырырга кушкан. “Авыз ачтырган кеше җәһәннәм газабыннан котылыр, Аллаһы Тәгалә белеп һәм белми кылган гөнаһларын ярлыкар”,–диелә изге Коръәндә.**

Изге аебызда уразаларыбызны тотып, өсләребездәге зур бурычларны үтибез. Нурлы, чиста, матур мәчетләрдә тәравих намазына йөрибез. Уразабызның 26нчы көнендә Акман авылында бик зурлап ифтар мәҗлесе узды. Безне Мисбах хәзрәт Гатин каршы алды. Мәчет эчендә узуга мине үзгә бер җылылык биләде: җанга шундый рәхәт, әйтерсең бирегә илаһи шәфкатьлелек орлыклары сибелгән иде. Килгән кешеләр барсыда пакьлек җәймәсендә тибрәлгән кебек тоелды миңа. Саф-саф булып килгән ак күлмәкле, чиккән түбәтәйле абыйларны, апаларны, яшьләрне күрүгә шатлыгым эчемә сыймады. Мисбах хәзрәт Гатин барыбызны бәйрәм белән котлады. Наил хәзрәт Вахитовның риваяте дә тормыштан алынган иде. Мәҗлес азан әйтү белән башланып, аннан соң өстәлдәге ризыклардан авыз ачу һәм Ахшам намазы уку белән дәвам итте. Илдар Котдусовның моңлы азан тавышы йөрәкләргә үтеп керерлек иде. Мисбах хәзрәтнең кеч-кенә генә оныгы сүрәләрне моңлы итеп көйләп бирде. Габдрахман хәзрәтнең кызы Мәрьям шаккатырды. Ул күп кенә Коръән сүрәләре белә икән.

Мәдрәсә директоры Габдрахман хәзрәтнең вәгазен халык йотлыгып тыңлады. Рамазанның күңелләрне нечкәртә торган ай, кылган гамәлләргә нәтиҗә ясау, сабырлык, гафу итү ае икәнлеге турындагы фикерләр, аять-хәдисләр белән ныгытылып, бөтен мәчеткә яңгырап торды. Рамазан аенда шулар турында еш-рак уйланырга җай чыга, шушы фарыз гамәл аркылы дингә якынаючылар торган саен арта бара. Аллага шөкер, ил-көннәребез тыныч, дөньяларыбыз җитеш, үзебез сау-сәламәт. Аш-су, табын кирәк-ярагы әзерләү эшләрен шушы мәчеткә йөрүче апалар хәзерләгән. Апаларга Алланың рәхмәте булсын. “Тоткан уразалары бәрәкәтендә иман-ихласлыклары арта торсын, хак Тәгалә, бу мәҗлесне оештыручыларга җиңеллекләр генә китерсен”–дигән теләкләрне монда килгән һәркем кат-кат кабатлады. Рамазан аеның биргән сабырлыгы һәркайсыбызга җитсен, кылган гамәлләрне, аның дәрәҗәсенә карап, дәресләргә язсын. Бу матур традиция югалмасын, елдан-ел киң колач алсын иде.

..........................................

**ФИРАЯ МИНГАЛИЕВА.**

## Сорау илә җавап

### УРАЗАНЫ КАЗА КЫЛУ

**С: Рамазан аеның каза уразаларын рамазан ае беткәч үк каза кылырга кирәкме?**

Ж,: Бу шарт булып килми, кайчан теләсә шунда каза кылырга мөмкин.

**С: Әгәр кеше каза кылуын икенче рамазан ае башына кадәр сузып килсә, аңа нишләргә?**

Ж,: Әүвәл башланган рамазанның уразасын тотарга, аннан соң калдырган көннәре өчен каза кылырга тиеш.

**С: Бер кеше үлгәннән соң рамазан аеннан каза уразалары калган булып, үзенең милкеннән кәффарәт түләргә васыять итеп калдырган булса, аның вәкиленә нишләргә?**

Ж,: Мондый васыять үлгән кешенең милкеннән 1/3 өлешен алып түләнелә. Һәрбер калдырган көн өчен ярты сагъ бодай яки бер сагъ арпа, хөрмә белән бер мескенне ашатырга кирәк.

### НӘФЕЛ УРАЗАЛАРЫ

**С: Нинди көннәрдә нәфел уразаларын тоту тыела?**

Ж,: Елның биш көнендә: ураза һәм корбан гаетендә, корбан гаете артыннан килүче 3 көндә нәфел уразасын тотарга ярамый.

**С: Нинди дә булса нәфел уразаларының башка уразалар алдында фазыйләтләре бармы?**

Ж,: Әйе, бар. Һәм бу хакта хәдисләрдә әйтелә.

Гайшәдән (аңардан Аллаh Тәгалә разый булсын) риваять ителә: «Аллаhның рәсүле (саллаллаhу галәйhи вәсәлләм) дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә ураза тотты». (Тирмизидән китерелә.)

Әбү Һөрайрадан (аңардан Аллаh Тагалә разый булсын) риваять ителә: «Аллаhның рәсүле (саллаллаhу галәйhи вәсәл¬ләм) әйткән: «Эшләр дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә карала һәм минем эшем ураза тоткан хәлемдә каралуын телим».

Шулай ук Әбү Һөрайра (аңардан Аллаh Тәгалә разый булсын) Аллаhның рәсүле (саллаллаhу галәйhи вәсәлләм) тулган ай көннәрендә өйдә дә вә сәфәрдә дә ураза тотуын риваять итә. (Ән-Нәсаидән китерелә). Әбү Катададән риваять ителә: «Аллаh Тәгаләнең рәсүле (саллалла галәйhи вәсәлләм) әйткән: «Гарәфә көнендә тоткан ураза өчен Аллаh Тәгаләгә минем киләсе елымдагы вә аннан соң тагын бер елымның гөнаhларын гафу итәр дип өметләнәм. Ә Гашура көнендә тоткан ураза өчен Аллаh Тәгалә киләсе елымның гөнаhларын гафу итәр дип өметләнәм».

Әбү Әюп әл-Ансари (аңардан Аллаh Тәгалә разый бул¬сын) риваять итә: «Аллаhның рәсүле (саллаллаhу галәйhи вә¬сәллəм) әйткән: «Кем Рамазан аенда һәм шәүвәл аеның 6 көнендә ураза тотса, гомере буе ураза тоткан кебек булыр».

### ӘЛ-ИГЪТИКАФ

**С: Нәрсә ул игътикаф?**

Ж,: Игътикаф — ул мәсҗедтә ният белән калу. Рамазан аенда 10 көн мәсҗедтә тору сөннәт әл- мөәккәдә. Ният кылганнан соң бер сәгать вакыт кадәр мәсҗедтә калу мөстәхәб. Ният кылынгач мәсҗедтә калу ваҗиб.

**С: Кеше мәсҗедтә берничә көн калырга ният кылса, аңа төнгә мәсҗедтә калырга ваҗибмы?**

Ж,: Игътикаф мөстәхәб яки ваҗиб булса да, барыбер әзлексезлекне сакларга кирәк.

**С: Кайчан игътикаф ваҗиб була?**

Ж,: Әгәр дә кеше мәсҗедтә калырга нәзер итсә, игътикафны үтәү ваҗиб була.

**С: Әгәр дә кеше мәсҗедтә бер көн калырга нәзер итсә, аңа төнне анда уздырырга ваҗибмы?**

Ж,: Әйе, аңа төнгә дә анда калырга кирәк.

**С: Игътикафта булганда нәрсәләр тыела?**

Ж,: Жимагъ кылу һәм бу хәлгә китерүче барлык гамәлләр дә тыела. Әгәр үпкәндә һәм назлаганда мәни чыкса, хәтта кеше онытылып яки төнлә белән булса да, ул чакта игъ¬тикаф бозыла һәм кәффәрәт кылырга кирәк.

**С:Игътикафта булганда мәсҗедтән чыгарга рөхсәт ителәме?**

Ж,: Бары тик бик кирәк булган очракларда гына, мәсәлән, олы һәм кече хаҗәтен үтәү өчен. Әбү Хәнифә (аңа Ал¬лаh Тәгаләнең рәхмәте булсын) фикеренчә, әгәр кеше сәбәпсез мәсҗедтән бер сәгатькә яки артыгракка чыкса, игътикафы бозыла. Аның укучылары бу срокны ярты көнгә кадәр озынайталар.

**С: Әгәр берәү игътикафта җомга намазы укылмый торган мәсҗедтә булса, аңа җомга намазын ничек укырга?**

Ж: Җомга намазы вакыты җитү белән ул җәмигъ мәсҗедкә бара һәм анда кешеләр белән бергә укый. Җомга намазы тәмамлануга кире кайтып үзенең игътикафын дәвам иттерә.

**С: Игътикафта булганда нәрсәләр рөхсәт ителә?**

Ж: Мәсҗедтә йокларга, ашарга һәм эчәргә, малны мәсҗедкә кертмичә сатуалу, әшәке һәм буш сүзләрсез генә сөйләшергә рөхсәт ителә.

**Газетада Аллаhы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 100 данә.**